# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 1** **23 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Туйкә авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 23 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

« Сез, 2020 елда Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 (Ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яшьләр, Гагарин, Киров урамнары юлларына вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Туйкә авылы урамнары исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу;
- Туйкә авылы урамнарына яктырткычлар, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешүе буенча эш өчен түләү;
- Туйкә авылында юлларны кардан чистарту;
- үзәкләштерелгән чыганаклардан эчә торган суны анализлау: «Сугышлы чишмәсе»;
- Туйкә авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Туйкә авылы юлларының техник паспортларын ясату;
- Туйкә авылы зиратларынын җир кишәрлекләрен ызанлау; җирләрнең категорияләрен үзгәртү;

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 340 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 184 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 184 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче Туйкә авылында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: « Сез, 2020 елда Түйкә авыл җирлеге Түйкә торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яшьләр, Гагарин, Киров урамнары юлларына вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Туйкә авылы урамнары исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу;

- Туйкә авылы урамнарына яктырткычлар, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешүе буенча эш өчен түләү;

- Туйкә авылында юлларны кардан чистарту;

- үзәкләштерелгән чыганаклардан эчә торган суны анализлау: «Сугышлы чишмәсе»;

- Туйкә авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;

- Туйкә авылы юлларының техник паспортларын ясату;

- Туйкә авылы зиратларынын җир кишәрлекләрен ызанлау; җирләрнең категорияләрен үзгәртү".

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.